**“Без, варисың синең Татарстан!”**
**5 нче сыйныфларны вариска кабул итү.**

**Максат:** Балаларда Татарстанның киләчәген тәэмин итүдә үзләреннән өлеш кертергә теләк тудыру; аларда үз-үзләре, башка кешеләр, киләчәк буыннар алдында һәм үз эшчәнлегең өчен җаваплылык хисе тәрбияләү, ТВБ оешмасы турындагы белемнәрен ныгыту.

# Җыен барышы

**Сәламләү.**

Кадерле укучылар! Бүген без бергә эшлиячәкбез һәм эшләве рәхәт булсын өчен кулларны тотышыйк һәм бер-беребез белән елмаеп сәламләшик *(түбәндәге сүзләрне кабатлыйлар):*

Йөрәктән чыккан сәлам җибәрик *(кулларын тотышалар)*

Барчабыз бергә һәрчак дус булыйк.*(куллар тотынышкан хәлдә алга сузыла)*

**Ә хәзер сүзне отряд командирына бирәбез.**

Безнең исем:________

Безнең девиз:_______

Безнең җыр:________

Без варислар отряды, без бүгенге сборга әзер!

1. **Игътибарлыкка уен.**

Укучылар, игътибарлылыкка уен тәкъдим итәм

**<u>Вожатый</u>: Кадерле укучылар! Сез эзтабар кагыйдәләрен төгәл үтәп, варис булырга әзерләндегез.Татарстан варислары Берлегенең традицияләрен, девизларын өйрәндегез. Менә бүген шул белемнәрегезне тикшереп китәрбез.**

**Аңарчы әйдәгез, башта үзегез белән танышыйк!**

1. Безнең класс тату класс,
Юк!- дидек начарлыкка.
Өстәвенә һәркайсыбыз
Беркадәр начальник та.

2.Сугышмыйбыз, елашмыйбыз,
Бик тәртипле йөрибез.
Бик яхшы билгеләр алып
Укып яткан көнебез.

3. Карлар яуса ява бирсен,
Чалт аяз көн миңа бүген.
Иң шатлыклы көнем бүген
Мин ВАРИС булам бүген.

4. Шатланып ачып керәмен,
Мәктәп ишеген.
Белемнең зур көч икәнен
Белгән кеше мин.

5. Шатланып ачып керәмен,
Мәктәп ишеген.
Бар көчемне биреп уку
Минем төп эшем.
Якты көннән туймыйбыз.
Кулны-кулга чаба-чаба,
Бии-бии җырлыйбыз.

**<u>ЖЫР: “Маленкая страна”</u>**

7. Күңелләр шатлыклы бүген,
Без булабыз ВАРИСлар.
Күргәннәр сокланып калсын,
Без бәхетле балалар.

8. Килер бер көн, мәктәпне дә,
Тәмамлар вакыт җитәр.

6. Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Һәркайсыбыз төрле якка
Юл алып ерак китәр.

9. Укуда без алдынгылар.
“5”ле генә алабыз.
Эшебездә дә уңганнар
Бакчабызга карагыз.

10. Ә хәзергә без укыйбыз
“5”леләр ала-ала.
Без укыйбыз икенчедә,
Класста 7 бала.

**<u>Вожатый:</u>** Булдырдыгыз, бик матур сөйлисез, җырлыйсыз да икән.
Инде сынауларны башларбыз. Сезнең һәрберегезнең алдында 1 дән алып 5 кә кадәр саннар ята. Мин сезгә сораулар укыйм, Сез миңа бу плакаттагы җавапларның кайсысына нинди сан туры килә, шул санны күтәрәсез. (Магнит тактага җаваплар язылган плакат куела).

| |
|---|
| **Плакат:**<br>**1.Гражданлык.**<br>**2.Дөреслек.**<br>**3.Игелеклелек.**<br>**4.Үсеш.** |

**<u>Вожатый:</u>** **Варислар берлеге әгъзаларының законнары һәм традицияләре – алар үз-үзеңне тоту кагыйдәләре ул. Аларны һәркем үтәргә тиеш.**
(Вожатый сорауларны укый**)**

1. **Варис тугрылыклы иптәш, олыларга һәм кечкенәләргә булыша. Бу нинди традиция? ( 3 )**
2. **Варис-ул үз республикасын ярата, аның лаеклы гражданы булырга омтыла. (1)**
3. **Варис дөреслек, хаклык өчен кыю көрәшә. ( 2 )**
4. **Варис күп белергә, көчле һәм җитез булырга омтыла. ( 4)**

(Дөрес җавап биргән балаларга жетоннар бирелә).

**<u>Вожатый</u>**: Икенче ТУРны башлыйбыз. Плакатка игътибар итегез.

| |
|---|
| **Плакат: 1. Һәрвакыт әзер!**<br>**2. Һәркөнне игелек кыл!**<br>**3. Көн саен яхшылык кыл!**<br>**4. “ДУСЛЫК”.** |

**<u>Вожатый:</u>** **Варислар девизы кайсы? ( 1 )**
**Варислар өндәмәсе нинди? ( 3 )**
**Мәктәп укучылары берлегенең исеме ничек? ( 4 )**
**Ул оешманың девизы ничек? ( 2 )**
(Дөрес җавап биргән балаларга жетоннар бирелә).

**<u>Вожатый</u>**: “Йолдыз сәгате”нең 3 нче туры. Сезгә төсләр бирелгән. “Мирас юлы” программасы нигезендә бу төсләр нәрсә аңлатканын әйтергә кирәк.

| |
|---|
| **Плакат: 1. Зәңгәр.**<br>**2. Яшел.**<br>**3. Кызыл.** |

**<u>Вожатый</u>**: **<u>Безнең</u> символлар -- ЗӘҢГӘР,. ЯШЕЛ, КЫЗЫЛ**.
-- **<u>Игелеклелек төсе ул</u>. Кешеләргә игелек кылучы, аларга үз җаннарының җылысын өләшүче булган күңелнең бер чаткысы. ( 3 )**
-- **<u>Безгә дөрес юл күрсәтүче төс.</u> Сәяхәттә генә түгел, тормышта да дөрес юнәлеш сайлый белү, юлдан читкә тайпылмау кирәк. ( 1 )**
-- **<u>Җир шарыбыз төсе.</u> Аның биш кисәгендә дә кешеләр, диннәре, милләтләре, инанганлыклары нинди булуга карамастан, тыныч һәм бәхетле яшәргә телиләр.( 2 )**
(Дөрес җавап биргән балаларга жетоннар бирелә).

**Вожатый**: Укучылар, инде **финал** өлешенә дә килеп җиттек. Бу ярышта барыгыз да бик күп жетон алыр дип уйлыйм. Игътибар! Чираттагы ярыш – сүзләр төзү ярышы.

| |
|---|
| **Плакат: К А Й Г Ы Р Т У Ч А Н Л Ы К** |

**Вожатый**: Менә шушы сүздәге хәрефләрдән **яңа сүзләр төзергә** кирәк.
Сезгә 1 минут вакыт бирелә. (Укучылар сүзләр төзиләр. Соңыннан кем күпме сүз язган – тикшерелә. Дөрес җавап биргән балаларга сүзләр санынча жетоннар бирелә).
**Вожатый**: Инде нәтиҗә ясарга вакыт җитте. Һәр укучы жетоннарын саный. Әгәр жетоннарыгыз ___ артса, сез ВАРИС булырга лаек дигән сүз. (Жетоннар саны билгеләнә).

**Вожатый**: **Укучылар, дөрестән дә, Сез варис булырга лаек икәнсез. Сезне ВАРИСлар сафына кабул итәбез. Рәхим итеп алга чыгып басыгыз!** (Балалар тезелеп басалар) **ВАРИСларның тантаналы вәгъдәсен беләсезме?** Я, әйтегез! (Укучылар хор белән әйтәләр: **Мин, --------, үзем теләп Татарстан варислары Берлегенә керәм, варисларның законын һәрвакыт төгәл үтәргә сүз бирәм. )**

**(** Галстуклар бәйләү тантанасы.)

**6.Җыр өйрәнү “Без варисың синең,Татарстан!”**
**7.Йомгаклау.**
. **Вожатый**: Кадерле ВАРИСлар! Сезне тантаналы көнегез – варислар сафына кабул ителүегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә фән нигезләрен “4” һәм “5”легә үзләштереп, укуда һәм иҗатта тырыш булуыгызны, безгә лаеклы алмаш булып үсүегезне телибез. Дружинада, отряд эшчәнлегендә актив катнашырсыз, мәктәпнең иң үрнәк, тату һәм дус отряды булып калырсыз дип ышанып калабыз.

**Саубуллашу.** *(кулларны өскә күтәреп)*
Безнең йөрәкләрдән чыккан ялкын сүнмәсен, сүрелмәсен, алдагы эшләребезгә яңа көч,дәрт өстәп торсын.